РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ АРТАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район,
д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
24.09.2018 г.

КАРАР
№18

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю һәм аны куллану буенча җирле референдум билгеләү турында

"Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында" 12.06.2002 №67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясына, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында" 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьялары, Татарстан Республикасының "Җирле референдум турында" 24.03.2004 №23-ЗРТ 18 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, Арташ авыл җирлеге Советының 21.09.2018 №16 "Референдум уздыру инициативасы турында" карары, Арташ авыл җирлеге башкарма комитетының 21.09.2018 №22 "Референдум уздыру инициативасы турында" карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю соравын кертү буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

"Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Арташ авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Ике Басу Арташ авылында чишмә һәм чишмә тирәсен төзекләндерү;
- Язлы Арташ авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Большой Арташ авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;

ӘЙЕ ЮК"

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Арташ авыл җирлеге башлыгы А.Р.Әгъләмҗанов